Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№9 (102)

27 март 2014 ел

# КФУ студенты – «Нәүрүз гүзәле»!



Кыш белән яз очрашкан көндә Уфаның «Нур» татар дәүләт театрында республиканың районнарыннан һәм шәһәрләреннән финалга үткән 12 кыз «Нәүрүз гүзәле» конкурсында көч сынашты. Унике көн дәвамында актерлык осталыгы, вокал, хореография, пластика дәресләре алган сылулар арасында мәктәп укучылары, студентлар, төрле өлкәдә эшләүче кызлар бар иде. Алар татар телен, мәдәниятен, милли гореф-гадәтләрне белүләрен, җыр-биюгә осталыкларын күрсәтте.

✦ Фотода: Гран-при иясе Идарә һәм территориаль үсеш институты студенты Алинә Гыйззәтуллина.

## Вакыйгалар эзеннән

Юридик факультетның Халыкара һәм Европа хокукы кафедрасы студенты **ФӘРИДӘ ВӘЛИУЛЛИНА** хатын-кызлар тормышын өйрәнү буенча үткәрелгән БМО комиссиясенең **58 СЕССИЯ УТЫРЫШЫНДА КАТНАШТЫ**. Чара БМОның Нью-Йорктагы штаб-квартирасында үтте. Ф.Вәлиуллина кандидатурасы Кеше хокукларын яклау һәм кызыксындыру ассоциациясе федерациясе тарафыннан расланган. Делегация составында Норвегия, Польша, Черногория һәм Нидерланд вәкилләре дә бар иде.

• • • •

**17-23 МАРТ** көннәрендә Санкт-Петербургта **«МӘДӘНИ БАШКАЛА» V ХАЛЫКАРА АЧЫК БӘЙГЕ ҮТКӘРЕЛДЕ**. Анда Яр Чаллы институтының «Сәйяр» халык бию ансамбле Гран-прига лаек булды. Катнашучылар вокал, хореография, инструменталь башкару, театр, мода театры һәм оригиналь жанр юнәлешләре буенча көч сынашты. Һәр юнәлешнең үз җиңүчесе билгеләнде.

• • • •

**25 МАРТ** көнне КФУның Яр Чаллы филиалында **ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬ ЛИГА**ның 2013-2014 елгы сезонының **V УЕНЫ БУЛЫП УЗДЫ**. Ике тур нәтиҗәләре буенча абсолют җиңүче дип «Двукратные» командасы табылды. Икенче урынга «Амбарбия Кергуду» командасы лаек булды. Өченче урын – «Лучшая академичесая группа»ныкы. Җиңүчеләр факультетара КВН уеннарына билетлар белән бүләкләнде һәм Казанга бару мөмкинлегенә ия булды.

• • • •

Шушы көннәрдә Психология һәм мәгариф институтында Дрезден техник университетының Педагогика институты белгече Dr. Dr.-Phil. **Ю.КОЙНОВОЙ-ЦЁЛЬНЕР**ның **ВИЗИТЫ ТӘМАМЛАНДЫ**. Визит барышында үзлектән өйрәнүне активлаштыру, мәгариф сыйфатын үстерү мәсьәләләренә багышланган лекцияләр, түгәрәк өстәлләр уздырылды.

• • • •

**25 МАРТТА КФУ**га Фулбрайт программасының Россиядәге директоры **ДЖОЭЛ ЭРИКСОН КИЛДЕ**. Визитның төп максаты Фулбрайт программаларының 2015-2016 елга Россия гражданнары өчен яңа конкурсын тәкъдир итү иде. Әлеге программа Россиядә инде 40 елдан артык эшләп килә. Шушы вакыт аралыгында Фулбрайт программасы ике меңгә якын Россия профессоры, укытучылары һәм яшь белгечләренә яңа фәнни контактлар урнаштыру, укуларын дәвам итеп, стажировка узу мөмкинлеге тудырды.

• • • •

Шушы ук көнне **КФУ**га Россиянең Мәгариф һәм фән министры **Д.ЛИВАНОВ КИЛДЕ**. Татарстанның Мәгариф һәм фән министры **Э.ФӘТТАХОВ** һәм КФУ ректоры **И.ГАФУРОВ** юлдашлыгында ул Фундаменталь медицина һәм биология, Физика институтлары лабораторияләре белән танышты, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Казан лингвистика үзәгенә барды. Министр «Ана теле» проекты, аны укыту программасы һәм аның бюджеты белән кызыксынды. Ул «Ана теле» аналогиясе буенча рус теленә өйрәтү мөмкинлеген дә күздә тотарга кушты.

**24 МАРТТА КФУ**да **«РОССИЯ ИЗРАИЛЬ: МӘДӘНИ** һәм **ФӘННИ ДИАЛОГ»** дип исемләнгән Халыкара фәнни-гамәли **КОНФЕРЕНЦИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕН БАШЛАП ҖИБӘРДЕ**. Әлеге чара Казанда 23-25 мартта үтә торган Яһүд китабы көннәре кысаларында уздырыла. Университетыбыз галимнәрен һәм студентларын Россиянең яһүд җәмгыятьләре Федерациясе премиясе лауреаты һәм «Ел кешесе» М.Гринберг, яһүд мирасы музее директоры А.Энгельс, Израиль дәүләтенең Россиядәге вәкиллегенең беренче сәркатибе Ш.Воскобойник, Татарстан яһүди милли-мәдәни автономиясе президенты М.Скоблионок сәламләде, катнашучылар алдында чыгыш ясады.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Эшлекле сөйләшү

# «Куйган максатларга ирешәбез!»

Динә МӨХТӘСИПОВА

21 март көнне фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиев Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты җитәкчелеге белән очрашты.





Утырышта институт директоры **Рәдиф Җамалетдинов** 2013 елга нәтиҗәләр белән таныштырды һәм 2014 елга планнар турында сөйләде. Чыгышында җитәкче институт эшчәнлегенең уңышлы һәм бик үк уңышлы булмаган якларына тукталды. Соңгы еллардагы үзгәрешләр нәтиҗәсендә, институтта шактый гына оптимальләштерү эшләре башкарылган. 40 кафедрадан 28 кафедра калган, профессор-укытучылар составы 63 штатка кыскартылган. 2013 елда исә, 17 кафедра, 3 бүлек калдырылган, укытучылар составы 55кә кыскартылган. Институтка карый торган 33нче номерлы бинадагы актлар залы лекция аудиториясе итеп үзгәртелгән. Хәзерге вакытта аны микрофоннар һәм мультимедиа җиһазлары белән тулыландыру эшләре алып барыла икән.



Институт эшчәнлегенең кимчелекле ягы итеп күп кенә укытучыларның Scopus һәм Web of Science базаларына кергән журналларда басылган мәкаләләренең саны аз булуны исәпләргә кирәк. «Бу кимчелекне бетерү өстендә дә актив эшлибез. 2012 елда 3 мәкалә басылган иде, 2013 елда бу күрсәткеч 9га җитте. Ел башлануга гына да карамастан, быел 9 мәкалә чыгарырга өлгердек. Ел ахырына 120 мәкалә бастыру максатын куйдык», – дип белдерде директор.

Институтның көчле яклары да шактый. Профессор-укытучылар составының фәнни үсеше, бай тарихи традицияләр, халыкара конференцияләрнең шактый еш уздырылуы, тел, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге уңышлар, студентлар тормышына зур игътибар бирелү – болар һәммәсе институтның дәрәҗәсен күтәрә. Студентлар республика күләмендә генә түгел, Россия, халыкара дәрәҗәдәге чараларда да актив катнаша һәм зур җиңүләр яулый. Институтның Татарстан Республикасы хөкүмәте белән хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә, аның алдында зур мөмкинлекләр ачыла. Әйтик, дөнья стандартларына җавап бирә, өч телдә чыга торган халыкара фәнни «Tatarica» журналының беренче саны әзер, ул якын киләчәктә киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителәчәк. «Ана теле» онлайн-мәктәбе ярдәмендә татар телен тәүлекнең теләсә кайсы вакытында, теләсә кайсы урында өйрәнеп була. Киләчәктә рус телен өйрәтү буенча шундый ук проект әзерләү планлаштырыла.

«Квантитатив лингвистика буенча проектларны тормышка ашыру институтның фәнни-тикшеренү өлкәсендәге эшчәнлегенә зур йогынты ясаячак. И.А.Бодуэн де Куртене исемендәге лингвистик үзәк базасында уртак тикшеренүләр уздыру өчен, Даниядән танылган лингвист Сорен Вихман чакырылачак. Шулай ук нейролингвистика буенча әзерләнгән проектларга да өметләребез зур», – диде Р.Р.Җамалетдинов. Чыгышын йомгаклап, институт эшчәнлегенә начар йогынты ясый торган кайбер факторларга да тукталды. Алар арасында РФендә гуманитар фәннәрнең приоритетлы юнәлешләр составында булмавы, абитуриентларның кимүе, филология һәм сәнгать өлкәсе буенча керергә теләүчеләрнең аз булуы һ.б. «Без барыбер куйган максатларга ирешәбез. Әлегә без авыр юлның башында гына, ләкин тырыш һәм бердәм коллектив белән алда торган бурычларны хәл итәрбез дип ышанам», – диде директор.

Чыгыштәмамлангач, проректор **Д.Нургалиевка** сүз бирелде. «Без үзгәрешләр заманында яшибез. Алар бездә генә түгел, бөтен дөньяда бара. Якын киләчәктә хәтта күз алдына да китермәгән үзгәрешләр булачак. Бу яңа буын, мәгариф өлкәсе һ.б. белән бәйле. Шуңа күрә үзебезгә дә үзгәрергә, максат-бурычларны яңадан куярга, нәрсә кирәклеген аңларга тиешбез. Университетның төп максаты булып, студентларны, укып бетергәч, белгечлеге буенча эш табып, тиз арада зур уңышка ирешергә өйрәтү тора. Алар бәхетле булырга тиеш. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты соңгы ике елда танымаслык булып үзгәрде. Ләкин IT өлкә буенча үзләштереп бетерәсе нәрсәләр бар. Хәзер бөтен дөнья шул ритмда хәрәкәт итә. Филология белән бәйле юнәлешләрне дә IT-технологияләр белән бәйләп була. Социогуманитар фәннәр буенча юл картасын әзерли башладык. Сездән яңа идеяләр, проектлар көтеп калабыз. Сезнең мөмкинлекләр күп, эшләгез генә», – диде проректор.

*Инна Басыйрова фотолары*

• Очрашу

## Автор иҗатын хуплау

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

КФУның Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә быелгы кандидатларның берсе, танылган татар язучысы Нурислам Хәсәнов белән очрашу булып узды.

Дистәдән артык китап – роман, повестьлар, күп санлы хикәяләр авторы булган Нурислам ага укытучы һәм студентларны үзенең иҗат остаханәсе белән таныштырды. Фикер алышуда катнашучылар аның «Бәхилләрме йөрәк?», «Инешемдә – гомер агышы», «Ак балык», «Тәкъдир», «Иңрәү», «Хакыйкать хакы», «Җан авазы» кебек әсәрләрендә җәмгыятебез өчен актуаль булган тәрбия, әдәп-әхлак проблемаларының гаять кызыклы язмышлар аша яктыртылуына басым ясадылар. Язучының бүгенге яшьләр тормышын, аларның психологиясенә үтеп кереп, халыкчан тел белән үтемле итеп тасвирлап бирә алу осталыгы хупланды. Бер үк вакытта, үзенең якташы булган халык язучысы Фатих Хөсни традицияләрен уңышлы дәвам итүче буларак, бүгенге тормыш чынбарлыгын кыю чагылдыра алуы да уңай бәяләнде.

Автор үз иҗатына бәйле төрле сорауларга җавап бирде. Очрашуда катнашкан студентлар һәм мөгаллимнәр Н.Хәсәновның заман рухын чагылдырган иҗаты Г.Тукай ис. дәүләт бүләгенә лаек дип, хуплауларын белдерде.

• Заман таләбе

# «Тәҗрибә – хакыйкать күрсәткече!»

Алинә САДЫЙКОВА

26 март көнне үз эшчәнлеген «Караш ноктасы» VII Халыкара студентлар конференциясе башлап җибәрде. Ул 3 көн буе дәвам итәчәк. Чара кысаларында «Студентлар күзаллавында Россиянең әйдәп бара торган югары уку йортларында белем бирү сыйфаты» темасына фикер алышачаклар.

КФУда студентлар катнашында күпсанлы чаралар, конференцияләр уза. Гадәттә, аларда университет шәкертләре фәнни эшчәнлек, фәнни эзләнүләре һәм табышлары белән уртаклаша. «Караш ноктасы» Халыкара студентлар конференциясе исә бүтән форматта үтә. Бирედә ел саен студентлар үзидарәсе органнары үсешенең актуаль мәсьәләләре турында сөйләшәләр һәм, шул рәвешле, Россия һәм БДБ илләре студентларының дуслык җепләре ялгана һәм ныгый.

Быелгы конференциянең эше өч секциягә бүленде: Россия һәм БДБ илләрендә фәнни һәм белем бирү процессларын трансформацияләүдә яшьләр һәм студентлар берләшмәләренең роле; гуманитар белем бирү һәм аның Россия вузларындагы халәте; югары белем бирүнең сыйфатын камилләштерү системасында студентлар берләшмәләренең эшчәнлеге.

Чараның пленар утырышын КФУ Студентлар иҗтимагый оешмалары һәм берләшмәләре Координацион Советы рәисе урынбасары **Олег Туманов** алып барды. Катнашучыларны КФУ президенты **М.Сәлахов**, РФ Дәүләт думасы депутаты **И.Гыйльметдинов**, Россиянең башка федераль университет вәкилләре, университетыбыз галимнәре сәламләде. Алар барысы да сайланган теманың актуальлеген һәм мөһимлеген ассызыклады.



Диана Поварова фотосы

М.Сәлахов әлеге конференциядә һәр елны катнаша икән. «Мин аның беренче утырышында ук булган идем һәм бу традицияне ел саен дәвам итәм. Шуны әйтәсем килә: проблеманы чишүгә төрле яктан килү– ул бик мөһим әйбер. Аны төрле караш ноктасыннан тикшерүне бик файдалы дип саныйм. Шуңа күрә, биредәге сөйләшүләр, тәҗрибә алышулар монда гына калмыйча, тиешле нокталарга барып җитсен иде. Тәҗрибә – хакыйкать күрсәткече. Хакыйкать эзләгез!» – диде ул.

И.Гыйльметдинов исә мондый чараларның кирәклегенә һәм файдалылыгына басым ясады: «Безгә эшләргә тели һәм эшли белә торган кешеләр кирәк. Шуңа күрә актив булыгыз. Кирәк вакытта үзебез ярдәм итәрбез. Без сезнең партнерларыгыз, иптәшләрегез һәм булышчыларыгыз!» – дип, студентларны рухландырып җибәрде депутат. И.Гыйльметдинов шулай ук Кырым студентлары белән дә элемтәләр булдырырга һәм аларга ярдәм итәргә өндәде.

КФУның Тел институты алман теле кафедрасы профессоры Фаина Ратнер сүзләренчә, югары белем бирүнең төп вазифасы – яңа җәмгыять булдыру. «Ул җәмгыятьнең әгъзалары да заман таләбенә туры килгән, һәр яктан үсеш алган булырга тиеш. Шуңа күрә, төп басымны шәхес тәрбияләүгә ясарга кирәк. Белем бирү системасы үзгәрмичә тора алмый. Бу зарури әйбер», – дип белдерде ул.

Алга таба чыгыш ясаучылар белем бирү сыйфатының нәрсәгә бәйле булуы турында үзләренең фикерләре белән уртаклаштылар.

Конференциянең программасы чараларга бик бай: анда пленар һәм секция утырышларынннан кала, мастер-класслар, түгәрәк өстәл, резолюция кабул итү белән бергә, нәтиҗәләр чыгару да кертелгән. Чарада катнашучылар өчен Казан шәһәренең тарихи һәм истәлекле урыннары: Казан Кремле, Раиф монастыре, КФУ планетарие, яңа спорт объектлары һ.б. белән танышу мөмкинлеге дә булдырылган.

● Җуелмас байлык

# «Ялкын» дигән гаҗәеп дөнья

**Илүсә АРИКЕЕВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Моннан нәкъ 90 ел элек Мәскәү шәһәрендә «Кечкенә иптәшләр» исемле журнал дөнья күрә башлый. Әлеге изге эшнең башында Муса Җәлил үзе тора.

### *Тамчы-тамчы тарих*

Балалар өчен махсус журнал чыгара башлау татар совет пионер матбугатының тууын хәбәр итә. 1928 елга кадәр гарәп графикасында чыккан басма латин графикасына күчә һәм «Октябрь баласы» исеме астында чыга башлый. 1933 елда Казанга кайткач, «Пионер каләме»нә әйләнә. Бөек Ватан сугышы барганда, журнал чыкмый тора. 1952 елдан «Пионер» исеме белән кабат басыла башлый. Әмма, бу елларда әлеге исем астында чыга торган басмалар күбәеп китү сәбәпле, журналның исеме «Ялкын» дип үзгәртелә.







Журнал тарихына Муса Җәлил һәм Абдулла Алиш исеме алтын хәрефләр белән язылган. Җәлилнең иҗат юлы, күп кенә язучышагыйрьләрнеке кебек, әлеге журналда башланып китә. Герой-шагыйрь «Кечкенә иптәшләр» һәм «Октябрь баласы» журналларының редакторы булып та эшли. Ул татар совет балалар матбугатын аякка бастыру өчен күп көч куя, үзенең иҗат дәртен кызганмый.

Җәлилнең көрәштәш дусты Абдулла Алиш озак еллар «Пионер каләме»нең җаваплы сәркатибе була. Үлемсез әкиятләрен Алиш нәкъ менә шул вакытларда иҗат итә.

Журналның 90 еллык тарихын барласаң, исең китәр! Нинди генә бөек язучылар, шагыйрьләр, популяр журналистлар эшләмәгән биредә?! Һәр яңа буын «Ялкын»га үз сулышын өрә, киләсе буыннар белән ике арага дуслык җепләре суза.

### *Безнең чор*

«Ялкын»ның үткәне турында журнал төпләнмәләре, анда эшләүче өлкән буын вәкилләре аша белсәм, журналның бүгенгесе – күз алдымда. «Аны без үзебез язабыз», – дисәм дә, һич арттыру булмас. «Ялкын» белән мин үземне хәтерли башлаганнан бирле таныш. Ә тәүге тапкыр редакциядә 2010 елда булдым. Шуннан бирле «Ялкын» дөньясында «яшим». Журналның үсмерләр редколлегиясе җыелышлары, министрлар, танылган йолдызлар белән узган очрашулар, бәйгеләр, «Сәләт-Раушан» аланында чыгарылган «Ялкын»ның баш мөхәррире булуым... Болар барысы минем «Ялкын»лы тарихым истәлекләре. Әле күптән түгел «Сәләт» илчеләре белән Әтнә районы мәктәпләрендә булып, «Ялкын» укучы малайлар-кызлар белән күрешеп кайттым. Әтнә балалары белән күрешү шатлыгы кимергә дә өлгермәгән иде, редакция коллективы белән Республика балалар китапханәсенә янә очрашуга киттек.

«Ялкын» – яшүсмерләр журналы, шуңа биредә эшләүчеләрнең дә күңеле һәрчак яшь. Баш мөхәррир Йолдыз Миңнуллина, журналистлар Фәйрүзә Мөслимова, Луиза Шарова, Искәндәр Хабибуллин, Эльвира Һадиева, Линар Закиров, фотограф Рөстәм Мөхәммәтҗанов – әнә шундый яшь, матур күңелле кешеләр.

Юбилей санын әзерләү процессында күрсәгез сез аларны! Журналның элеккеге баш мөхәррире Эльмира апа Закирова да биредә, аның махсус эш кушылган. Әнә, социаль челтәрдә Раилә апа Сабированың котлау хаты. Бүгенге көндә кечкенә Зөбәрҗәтне карап, өйдә утырса да, күңеле белән ул да безнең янда.

### *Бөтен Казан котлый*



Бу көннәрдә «Ялкын» журналының 90 яшьлек юбилее уңаеннан журналның үсмерләр редколлегиясе флеш-моб үткәрде. Яраткан «Ялкын»ыбызны яшьләрчә котлыйсы килде безнең. 90 кешелек командага туплanып, метрода «Ялкын»ны укыдык, Бауман урамында һавага 90 шар очырдык. Әлеге чара журналга реклама ясау гына түгел иде, әлбәттә. Флеш-моб татар яшьләрен берләштерде, аралашу мөмкинлеге бирде.

Юбилей уңаеннан әле алда тагын да зуррак, матуррак чаралар көтелә. «Ялкын» – безнең территория. Бергә булыйк, бергә ялкынланыйк!

***P.S.** Редакциябез исеменнән дә «Ялкын»лыларны уртак бәйрәмебез белән ихластан котлыйбыз. Иҗат чишмәгез саекмасын! Укучыларны сөендереп, озак еллар эшләгез!*

● Гамәл һәм гадәт

# «Мондый стипендия – тырышлык нәтиҗәсе»

26 март көнне Физика институтында Илдар Гыйльметдинов исемендәге стипендия тапшыру тантанасы үтте. Институт студентлары Рифкат Галиев белән Айгөл Хәйретдинова исемле стипендиягә лаек булып, РФ Дәүләт Думасы депутаты кулыннан диплом алу бәхетенә иреште.

Ун еллык тарихы булган әлеге стипендияне тапшыру күркәм традициягә әйләнгән. Быелгы юбилей тантанасы да җылы атмосферада узды. Абруйлы стипендияне яхшы билгеләргә генә укыган, җәмәгать эшләрендә актив катнашкан, спортта уңышлары булган нәкъ менә фәнни-педагогик белем бирү бүлеге студентлары ала. Илдар Ирек улы Гыйльметдинов та заманында Физика институтын тәмамлаган. Студент елларында ул, актив студентлар сафында булуы белән беррәттән, үзен күпкырлы шәхес, спортчы, талантлы укытучы итеп тә таныткан.

«Бу стипендия студентның матди хәлен әллә ни үзгәртмәсә дә, минемчә, студентта ниндидер теләк чаткысы, омтылыш кабынып китә. Бу бүлектә әзерләнә торган белгечләр, укытучылар – илнең киләчәге. Укытучы – бүгенге көндә иң кирәкле һөнәрләрнең берсе. Чыннан да, шундый катлаулы һәм җаваплы юлны сайлау белән сез зур хөрмәткә лаек. Мондый Дәүләт Думасы депутаты исемендәге стипендия һәркемгә бирелми. Моңа иң-иңнәр генә лаек», – диде И.Гыйльметдинов.

Физика институтының фәнни-белем бирү бүлеге җитәкчесе Гүзәл Гарнаева әйткәнчә, бу стипендияне алучыларның һәммәсе дә үз юлын тапкан. Мәсәлән, иң беренче стипендиант Нәфис Миннебаев – хәзер спортсмен, Универсиада чемпионы. Күп кенә стипендиатлар



Влад Михневский фотосы

Татарстан мәктәпләрендә физика, математика фәннәрен укыта, төрле оешмаларда җитәкче вазифасын башкара. Араларында, укуларын дәвам итеп, үзләрен фәнгә багышлаган студентлар да бар. «Стипендиягә лаек булганнарга мин алга таба да ярдәм итәргә әзер», – дип искәртте Илдар әфәнде.

Дөрестән дә, мондый стипендияләрнең әһәмияте зур. Нияз Җамалиев – узган елгы стипендиат. Ул да бу системаны файдалы һәм нәтиҗәле дип саный. «Әлеге стипендия, иң беренче чиратта, тырышлык нәтиҗәсе. Аны алгач, тагын да дәртләнеп, кызыксынып укый башлыйсың», – ди ул.

Чарада социаль һәм тәрбия эшләре буенча проректор Ариф Межведилов та катнашты. Ул, үз чиратында, шушы күркәм традициянең дәвамлы булуын, студентларга тырышлык, яңа ачышлар теләде.

И.Гыйльметдинов ис. стипендия алучылар саны тагын икегә артты һәм аңа инде барлыгы 38 студент лаек булды. Шушы матур традиция башка студентларга да стимул булып торсын иде.

● Сәләткә сәбәп кирәк

Материалларны **Илмир ВӘЛИЕВ** әзерләде



Влад Михневский фотосы

# Җиңү җиңел бирелми

22-23 мартта мәркәзебезнең IT-паркында Татарстанның студентлар һәм укучылар командалары арасында программалаштыру буенча XIV ачык турнир узды.

2000 елда старт алган әлеге турнирда 41 команда көч сынашты. Алар арасында Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург һәм Россиянең башка шәһәрләреннән килгән яшь программистлар да бар иде. «Турнирның географиясе киңәя, ә катнашучылар саны арта бара. Сайлап алу турларын да исәпкә алсак, безнең турнир аша биш меңгә якын катнашучы узды. Алар безнең киләчәгебез һәм күбесе инде әйдәп баручы белгечләр, бөтен Россия буйлап төрле оешмаларның IT-департамент җитәкчеләре. Шунысы куандыра: конкурсантларны әзерләү сыйфаты елданел камилләшә, ә көрәш җитдиләнә», – ди ICL КПО ВС компаниясе генераль директоры Виктор Дьячков.

Әлеге турнир студентларның программалаштыру буенча дөнья чемпионаты кагыйдәләренә таянып оештырыла. Тәкъдим ителгән бөтен мәсьәләләрнең чишелешен реаль вакыт режимында махсус сервис тикшерә. Нәтиҗәдә, тапшырылган эшләр турындагы мәгълүмат берничә секунд эчендә билгеле була.

Бирелгән эшләрне уңышлы башкарып чыгу, конкурсантлардан программалау өлкәсен белү белән беррәттән, математик әзерлекне, төрле алгоритмнарны һәм командада эшли белүне таләп итә.

Студентлар командалары арасында пьедесталның иң югары баскычын Moscow SU Trinity (М.В.Ломаносов – ис. МДУ), ә укучылар зачетында Урал федераль университетының махсуслаштырылган фәнни-белем бирү үзәге командалары яулады.

Республикабыз да бу өлкәдә югары уңышларга ирешкән яшьләрне читтә калдырмый. 2010 елдан башлап, бу турнирда ТР президенты премиясе бирелә башлады. 50 мең сум күләмендәге әлеге премия Татарстаннан катнашкан иң көчле студентлар һәм укучылар командасына тапшырыла. Быел исә аңа Kazan FU #1 (КФУ) һәм «Диванная аналитика» (122 номерлы гимназия) командалары лаек булды.

• Безнең тышлык

# КФУ студенты – «Нәүрүз гүзәле»!

Гүзәлия ГЫЙНИЯТУЛЛИНА,
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Яз сулышы белән җанга – наз һәм сөю, күңелгә – илһам, йөрәккә дәрт иңгән бер мәлдә борын-борыннан Нәүрүз бәйрәме уздырылган. Гореф-гадәтләргә тугры калып, быел Башкортстан Республикасында уникенче тапкыр «Нәүрүз гүзәле» конкурсы үтте.



«Нәүрүз гүзәле» бәйгесе финалында кызлар биш төрле сынау тотты. Иң элек алар бик кызыклы һәм үзенчәлекле итеп үзләре белән таныштырды. Аннан соң кемдер җырмоңга сәләтен, кайберләре биюгә осталыгын күрсәтте. Ана телендә матур сөйләүгә, милли гореф-гадәтләрне белүгә дә аерым игътибар бирелде.

Конкурсны оештыручылар – Башкортстанның Татар конгрессы, татар хатын-кызларының «Сәхипҗамал» төбәк иҗтимагый оешмасы, «Азатлык» яшьләр берлеге. Генераль химаячысы – «Берлек» татар иҗтимагый мәдәни-агарту оешмасы. Җюри белән Башкортстан Башкарма комитеты рәисе Халисә Мөхәммәдиева җитәкчелек итте. Мәртәбәле җюри әгъзалары арасында Башкортстанның мәдәният министры урынбасары Ранис Алтынбаев та бар иде. Бәйге-тамашага килгән Татарстан кунаклары, артистлар, зур шәхесләр аның дәрәҗәсен тагын да күтәрде.

Башкортстанның Татар конгрессы Башкарма комитеты әгъзасы Зәлия Ахунова әйтүенчә, татар кызлары йөз чибәрлеге, буй-сынга карап кына сайланмый, ә татар телен, милли гореф-гадәтләрне, аш-су пешерүгә осталыкта да сынау уза. «Гадәттә, матурлык конкурслары оештырганда, кызларны чишендереп, сәхнәдә йөртеп сайлап алалар. Моңа охшаш хәл бездә бөтенләй булмый, – ди Зәлия ханым. – Бу безнең халыкка хас күренеш түгел. Күп кызлар оялу аркасында бөтенләй дә килмәскә мөмкин. Ислам динендә дә бу катгый тыела. Шуңа күрә «Нәүрүз гүзәле»н, һәрвакыттагыча, милли рухта үткәрәбез. Бу шоу түгел, ә ана, бала тормышына багышлап театральләштерелгән матур тамаша».

Сынауларны уңышлы гына үтеп чыккач, кызларга бәя бирелде. Аларның һәркайсы җиңүгә лаек, шуңа күрә гүзәл затларга төрле номинацияләрдә бүләкләр тапшырылды.

Халкыбызның бүгенгесе белән киләчәген тоташтыручы, милләтебезнең иң акыллы, сөйкемле, леаклы кызлары кемнәр соң? «Нәүрүз гүзәле» исеменә Туймазы районының Кандра авылыннан 19 яшьлек Алинә Гыйззәтуллина лаек булды. Алинә безнең Казан федераль университетының Идарә һәм территориаль үсеш институтында икенче курста укый, инженер-эколог һөнәрен үзләштерә. Сылу кыз шулай ук «Дуслык алиһәсе» номинациясендә дә җиңеп чыкты. Бәйгегә әзерлек барышында, ул бердәм гаиләгә әверелгән төркемнең старостасы булган һәм кызларның һәркайсы белән уртак тел тапкан. Алинә нәкъ менә шушы номинациядә җиңү яулавына ныграк шатлана. Димәк, кызлар миңа таяна ала, ди ул. Алинә балачактан бирле бию, сәнгатьле сөйләм белән шөгыльләнә. «Мин сәхнәдә үстем», – дип елмая Алинә. «Нәүрүз гүзәле» үтеп китте, ләкин Алинәнең тагын ике матурлык конкурсында катнашасы бар. Алар: «Бөтенроссия студенткалары» һәм «Азия-Себер сылуы» конкурслары.

«Нәүрүз гүзәле» конкурсына мин җиңәргә бармадым, хәтта уемда да юк иде. Гомумән, мин үземнең гаиләм, туганнарым хакына катнашырга булдым. Чөнки аларның мине чын татар кызы итеп күрүләре илаһи көч бирде, дәрт-дәрман өстәде. Финалга әзерләнү вакытларында нинди генә кыенлыклар килеп чыкмасын, гел якыннарымның җылысын тоеп тордым. «Нәүрүз гүзәле» конкурсы мине бик күп нәрсәләргә өйрәтте, чыныктырды. Беренчедән, туган – татар телемне яхшырттым, татар халкының тарихы, гореф-гадәтләре буенча белемнәремне арттырдым һәм, иң мөһиме, яңа дуслар таптым».

Кызларга татар теле сабакларын укыткан Башкортстанның атказанган артисты Мәхмүт Фатыйхов әйтүенчә, быел бәйгедә катнашучыларның ана телен белүе узган еллар белән чагыштырганда югарырак: «Ә инде ун көн дәвамында алар татар телен тагын да камилләштерде һәм ана телебезнең нинди бай булуына инанды», – ди Мәхмүт әфәнде.

«Нәүрүз гүзәле» кебек конкурсларны ешрак үткәрергә кирәк. Алар безне берләштерә, таныштыра, киләчәк тормышка юл сала.

• Туган тел сагында

# Мин бит татар баласы!

Айзилә ГАЗИЗОВА, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Бу вакыт дигәннәре бигрәк тиз уза икән. Студент еллары, вакыт атына атланып, алга чаба. Вакытны туктатып булмый.

Без дә инде бүген – дүртенче курс студентлары. Бу ел безнең өчен үзенчәлеклерәк, чөнки беренче тапкыр үзебезне чын татар теле һәм әдәбияты укытучылары ролендә сынап карадык. Без дә мәктәп тормышы белән якыннанрак таныштык, көтеп алган беренче практикабызны үтеп кайттык. Мәктәпләрдән төрлебез төрле фикерләр, уйлар белән кайтты. Кемдер укытучы һөнәрен минем һөнәр, ди, ә кемдер исә, киресенчә, бу һөнәр миңа бик туры килеп бетми, ди.

Фикерләр төрле. Минем дә үз фикерем бар. Юк, мин алда әйтеп үтелгән ике төркем рәтенә кермим. Минем йөрәгемә башка уйлар тынгылык бирми. Сүз газиз туган телебез турында... Татар гимназиясендә татар теле һәм әдәбияты буенча практика үтеп кайткач, тиздән татар телен чынлап та «Кызыл китап»ка кертергә кирәк булачагына тагын бер кат инандым мин.

Юкка гына үз заманында Гаяз Исхакый бу проблеманы күтәрмәгәндер. Ә бөек, хәзер инде мәрхүм Туфан абыебыз Миңнуллин, конференцияләрдә, очрашуларда татар теленең бүгенгесе һәм киләчәге турында юкка гына янып-көеп сөйләмәгәндер. Минем дә күңелем сыкрый...

Сыйныфта унтугыз укучы. Шуларның унҗидесе – «чипчиста» татар балалары. Мин дәрес укытырга керештем. Татар гимназиясе булгач, рәхәтләнеп татар телендә дәрес алып барырмын, дип уйладым. Юк, андый бәхет миңа тәтемәде. Шул «чип-чиста» татар балалары, русчалатып: «Без сезне аңламыйбыз. Нәрсәгә кирәк безгә сезнең татар телегез?» – дип, авыз ачып утыралар. Өстемә кайнар су сиптеләрмени?! Ярар, дәресләремне русчалы-татарчалы итеп үткәрдем, ләкин эшемнең тәмен татымадым. Ә бары шушы киләчәк буын, телебез өчен борчылу хисләре генә кичердем.

Татар халкым, нигә һаман түбәнгә тәгәрибез без болай? Ник оялабыз без сандугач сайравыдай, йомшак, матур Ана телебездән? Сораулар күп. Ә кем гаепле соң?

Иң беренче чиратта, гаеп үзебездә. Туган телебезгә карата үзебез битараф булгач, безгә карата башка милләт, башка халыкларның мөнәсәбәте нинди булыр соң? Чын татар кешесенә ниндидер горурлык хисе белән: «Мин татарча белмим, аңламыйм!» – дип әйтү гадәти хәлгә әйләндемени хәзер? Мәсәлән, күп кенә татарлар белән татарча сөйләшә башласаң, алар шакката. Ә мин аларга гаҗәпләнәм. Бер-берен белән татарча аралашу чынлап та шулкадәр сирәк күренеш микәнни? Ә бит татар теле – туганлаштыра, араларны якынайта торган йомшак тел.



Киләчәк буынның әти-әниләре кая карый икән соң? Ник алар үз балалары белән яңгырашлы газиз ана телебездә сөйләшмиләр? Бу буын татар телен белми икән, аннан киләчәк буын татар теленең нинди тел икәнлеген дә әйтеп бирә алмаса?.. Гаҗәпләнергә кирәкми.

Минемчә, туган телгә карата мәхәббәт, хөрмәт, горурлану хисләре, иң беренче чиратта, гаиләдән башланырга тиеш. Әгәр дә гаилә белән мәктәп бергәләп бу юнәлештә эшләмәсә, татар теле һәм әдәбияты укытучылары гына телебезне саклап кала алмый.



«Ник кирәк соң ул миңа татар теле?» – дип, сораучыларга минем җавабым мондый: «Ничә еллар буе килгән тарихы сиңдә өзелмәсен өчен, синең буының аны күмеп куймасын өчен, үзең өчен кирәк!» Үз телеңне дә белми, ничек чит телләрне өйрәнергә кирәк?

Дусларым, газиз татар телебездән ваз кичмик! Аны киләсе буынга хәзинә итеп тапшыру – безнең төп бурыч.

Язмамны Галимҗан Ибраһимовның сүзләре белән тәгәллисем килә «Русча белү кирәк, үз телеңне белү тиеш». Бик дөрес сүзләр. «Әти», «Әни» сүзләрен, «папа», «мама» сүзләре белән алыштырыга юл куймыйк, зинһар!

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.